ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАЛОЦИЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ
ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Тел.: (84375) 39-3-35; 39-4-72, факс: (84375) 39-3-35, e-mail: MceI.Drz@tatar.ru,

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** *с.Малая Цильна* **КАРАР**

30 январь 2015 ел № 1

Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 ел, №67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, «җирле референдум турында» 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, Кече Чынлы авыл җирлеге Уставының 11 статьясы, "Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында" гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү " (2014 елның 14 гыйнварындагы 3 номерлы, 2015 елның 12 февралендәге 85 номерлы үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү буенча уртак инициативаны түбәндәге эш буенча тәкъдим итәргә:

"2015 елда Чүпрәле муниципаль районының Кече Чынлы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә үзара салым акчасын кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- Кече Чынлы авылының Тукай урамында юлларны карап тоту һәм ремонтлау-33 000 сум акча тотылган;

- Кече Чынлы авылының К. Маркс урамында юлларны карап тоту һәм ремонтлау-33 000 сум акча тотылган;

- Кече Чынлы авылының Ленин урамында юлларны карап тоту һәм ремонтлау-33 000 сум акча тотылган;

**«ӘЙЕ»** **«ЮК**.».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә һәм Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлегенең рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталын урнаштырырга.

Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Э.С.Хакимов